РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» мая 2022 ел г. Альметьевск № 1491

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районының Мәдәният идарәсенә гамәлгә
куючының аерым функцияләрен һәм
вәкаләтләрен тапшыру турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсенә (алга таба - Идарә) ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләргә карата функция һәм гамәлгә куючының вәкаләтләрен түбәндәге өлештә бирергә:

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы һәм гамәлгә куючы белән килештереп, барлык дәрәҗәдәге бюджетлар исәбеннән җирле бюджеттан субсидияләр рәвешендә кергән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга акчалар белән эш итү;

муниципаль биремне төзү һәм раслау, аны финанс белән тәэмин итү, муниципаль биремнең үтәлешен тикшереп тору, муниципаль мөлкәткә ия булуның, аннан файдалануның һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәү, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә мөлкәтнең билгеләнешен һәм сакланышын тикшереп торуны гамәлгә ашырырга, оператив идарә итү хокукында муниципаль учреждениеләргә беркетелгән мөлкәтне билгеләү буенча булмаган артык мөлкәтне тартып алу буенча тәкъдимнәр бирергә;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен кабул итү һәм эштән азат итү, аларга дисциплинар җәза бирү һәм кызыксындыру чаралары бирү, шул исәптән барлык төрдәге отпускларны бирү, хезмәт шартнамәләре (контрактлары) төзү;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә беркетелгән муниципаль күчемле мөлкәтне (транспорт чараларыннан тыш) яңадан бүлү, баланс бәясе 100 000 сумга кадәр (мең сум) һәм күчемле мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын раслау буенча карарлар кабул итү.

2. Идарәгә буйсынучы учреждениеләрнең исемлеген расларга (1нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып

Зак. № 305-2000

чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«18» июль 2022 ел №1491
карары белән расланган
1 нче кушымта

Идарәгә буйсынучы учреждениеләрнең исемлеген

Табл. №1

| №№ п/п | Учреждение исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 | «Әлмәт шәһәре Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 2 | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы»муниципаль бюджет учреждениесе |
| 3 | «Әлмәт туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 4 | «Ризаэддин Фәхреддин мемориаль музее» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 5 | «Әлмәт картиналар галереясе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 6 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Р.Н. Нәгыймов исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе |
| 7 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «3 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе |
| 8 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе |
| 9 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «2 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе |
| 10 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе |
| 11 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «2 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе |
| 12 | «Әлмәт шәһәренең «Нефтьче» мәдәният сарае» муниципаль автоном учреждениесе |
| 13 | Әлмәт муниципаль районының «2 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном мәгариф учреждениесе |
| 14 | «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәдәният идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 15 | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Элмэт» милли-мәдәни үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |

Район Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары
вазыйфаларын башкаручы Д.В. Косарев